**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

18.07.2019 | ПР-154

**Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләры хезмәткәрләрен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау турында**

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләренең авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга, терлекчелек тармагын үстерүгә стимуллаштыру максатларында Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1.Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләры хезмәткәрләрен бүләкләү турында Нигезләмәне расларга.

2. Комиссия составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 09.02.2018ел. №ПР-16 санлы «Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиелары хезмәткәрләрен бүләкләү турында» Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты карарының үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л. Р. Сираевага йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе | И.Ш.Бариев

**Актаныш муниципаль районының терлекчелек хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмә**

## I. Гомүми нигезләмәләр.

1.1 Терлекчелек хезмәткәрләрен бүләкләү ай саен 24 форма отчет йомгаклары буенча башкарыла һәм районның терлекчелек тармагын үстерү дәрәҗәсен, терлекләрнең продуктлылыгын арттыру һәм республика дәрәҗәсендә югары күрсәткечләргә ирешү максатларында эшләнә.

1.2 Җиңүчеләрне бүләкләүче һәм оештыручы булып Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты тора.

1.3 Бүләкләү акчалата формада башкарыла.

1.4 Финанслау район бюджеты хисабынан башкарыла.

## II. Бүләкләү максатлары.

2.1. Бүләкләү түбәндәге максатларда үткәрелә:

- Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы җитештерү хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен арттыруда кызыксындыру;
- авыл хуҗалыгы предприятиеләренең хуҗалык-финанс хәлен яхшырту;
- башкарылган эш өчен җаваплылыкны арттыру.

## III. Бүләкләнүчеләр.

3.1. Үз эшчәнлекләрендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы оешмалары белгечләре, хезмәт кенәгасе буенча белгечлекләре расланган булса, бүләкләнәләр.

Авыл хуҗалыгы предприятиесе бу Нигезләмәдә гамәлгә ашырылган продукциянең гомуми күләмендә 70 процентган да ким булмаган күләмдә, авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан кергән керемнең чагыштырма авырлыгы булган, Актаныш муниципаль районының агросәнагать комплексы структурасына кергән юридик зат аңлашыла.

3.2. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләренең түбәндәге категорияләре бүләкләнергә тиеш.

- зоотехниклар;
- ветеринар белгечләр;
- терлек үрчетү технологлары;
- ферма мөдирләре;
- эре мөгезле терлек ите җитештерү буенча ферма мөдирләре;
- авыл хуҗалыгы предприятиеләре.

## IV. Бүләкләү тәртибе.

4.1. Терлекчелек хезмәткәрләрен бүләкләү 24 форма отчет йомгаклары һәм комиссия карары буенча башкарыла.

4.2. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең зоотехникаларын бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- бер сыердан иң күп сөт савылган, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда югарырак булган,

- эре мөгезле терлек итенең иң югары күләме 1 башка 750 граммнан ким булмаган,

- 17 ае тулган тешеләрне исәпләү нигезендә каплатуны тәэмин иткән,

- лаборатор тикшеренүләр нигезендә баланслы ашатуны тәэмин иткән.

3 урын билгеләнә:

1 урын – 10 000 сум күләмендә премия;

2 урын - 7 000 сум күләмендә премия;

3 урын - 5 000 сум күләмендә премия.

4.3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ветеринар белгечләрен бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- узган ел белән чагыштырганда үлемне киметкән, үрчемгә карата үлем район күрсәткеченнән артык булмаган;

- каплату расчеты нигезендә буазлыкны тикшергән;

- бозаулаганнан соң 5 ай эчендә сыерларны каплату өчен сәламәтлеген тәэмин иткән;

- профилактик вакцинацияны вакытында үтәп барган.

3 урын билгеләнә:

1 урын – 10 000 сум күләмендә премия;

2 урын - 7 000 сум күләмендә премия;

3 урын - 5 000 сум күләмендә премия.

4.4. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең терлек үрчетү технологларын бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- каплатуга карата бозау алу 90%нан ким булмаган очракта;

- узган елга карата бозау алуны киметмәгәндә;

- бозаудан соң 60-90 көн аралыгында 90% ким булмаган каплату;

- билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә хисапларны алып бару, төзү (3 МОЛ, 10 МОЛ журналлары, буазлыкка тикшерү акты, сыерларның физик хәле турында стендлар, һ.б.)

3 урын билгеләнә:

1 урын – 10 000 сум күләмендә премия;

2 урын - 7 000 сум күләмендә премия;

3 урын - 5 000 сум күләмендә премия.

4.5. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ферма мөдирләрен бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- 1 сыерга иң күп сөт җитештергән һәм узган елның шушы чорына карата киметмәгән;

- тәүлеклек үсеш уртача 750 грамнан ким булмаган;

- терлек баш саннарын 98 % сакланышын тәэмин иткән;

- ай саен контроль савым үткәрүне тәэмин иткән; (сыерларның продуктлылыгы)

- атна саен санитар көн үткәрүне оештырган; (журналлар булдыру)

3 урын билгеләнә:

1 урын – 10 000 сум күләмендә премия;

2 урын - 7 000 сум күләмендә премия;

3 урын - 5 000 сум күләмендә премия.

4.6. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең эре мөгезле терлек ите җитештерү буенча ферма мөдирләрен бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- гомуми мөгезле эре терлек саны 200 баштан ким булмаган;

- терлек сакланышы 98% булган;

- ай эчендә 1 башка иң күп ит җитештергән, узган ай белән чагыштырганда киметмәгән һәм район күрсәткеченнән ким булмавын тәэмин иткән.

3 урын билгеләнә:

1 урын – 5 000 сум күләмендә премия;

2 урын - 3 000 сум күләмендә премия;

3 урын - 2 000 сум күләмендә премия.

4.7. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- 1 баш шартлы терлеккә узган ел белән чагыштырганда иң күп акча кереме керткән;

- 1 сыерга сөт сатуны арттырган;

- саткан сөтнең товарлылыгы 95% ким булмаган;

- 1 баш мөгезле эре терлеккә узган ел белән чагыштырганда күп ит җитештергән.

3 урын билгеләнә, беренче урынны алган хуҗалык күчмә символ белән бүләкләнә.

## V. Бүләкләү өчен авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен сайлап алу механизмы.

5.1. Бүләкләүдә катнашу өчен гариза булып, катнашучының эш күрсәткечләре турында җитәкче тарафыннан расланган белешмә тора, ул тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплы.

5.2. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренең белешмәләрен Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе раслый.

## VI. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү өчен билгеләү буенча комиссия.

6.1. Барлык категория хезмәткәрләрен бүләкләүгә билгеләү өчен, комиссия төзелә (алга таба - комиссия) һәм аның составы расланa.

6.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә: комиссия председателе, председатель урынбасары, комиссия сәркатибе, členнар.

- комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия утырышын үткәрә.

- комиссия рәисе урынбасары, рәис булмаган очракта аның вазыйфаларын башкара.

- комиссия сәркатибе комиссия әгъзаларына комиссия утырышы урыны, вакыты турында хәбәр итә, утырыш беркетмәләрен тутыра, документлар формалаштыра.

6.3. Комиссия утырышы, комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала. Комиссия әгъзалары утырышларда алыштыру хокукыннан башка катнашалар. Комиссия әгъзасының утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, ул каралучы мәсьәләләр буенча үз фикерен алдан язмача тапшырырга хокуклы. Бу очракта ул комиссия утырышында игълан ителә һәм утырыш беркетмәсенә теркәлә.

6.4. Комиссия карарлары комиссия составына кергән затларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тигез тавыш булганда комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

6.5. Комиссия авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләүне, әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты күрсәтелгән, ирешелгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән билгели. Иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән авыл предприятиеләре хезмәткәрләре бүләкләнерргә тиеш.

6.6. Комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана.

## VII. **Йомгаклау һәм бүләкләү.**

7.1. Комиссия беркетмәсе нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү өчен акча бүлеп бирү турында Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесенең күрсәтмәсе проектын әзерли.

7.2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе проекты түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

- бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
- билгән вазыйфасы;
- эш урыны;
- акчалата бүләкләү суммасы.

Финанслау чыганагы Актаныш муниципаль районы муниципаль программасының конкрет чарасын һәм бюджет классификациясе кодын күрсәтеп.

7.3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү өчен бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылышын, аларны кучерүнең дөреслеген һәм үз вакытында башкарылуын тикшереп торуны, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге гамәлгә ашыра.

Кушымта 1

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләре- зоотехниклар, ветеринар белгечләр, терлек үрчетү технологлары, ферма мөдирләре бүләкләү буенча кандидатларны карау комиссиясе составы.

Комиссия рәисе:
Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - Сираева Л.Р.

Комиссия членнары:
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Мирхайдаров А.А.,
Икътисад бүлеге җитәкчесе- Мирзашарипова О.М.
Актаныш районы ветеринария берләшмәсе җитәкчесе -И.Н.Ялалов

Секретарь:
1. ПМО УСХиП баш белгече–Шагиахметова Г.З.